| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.12.2025 № 774-П

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан, ачыкланган «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү, аның территориясе чикләрен һәм аны саклау предметын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 елның 27 ноябрендәге уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан, ачыкланган «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, (объект төре – һәйкәл) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертергә.

2. Әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин

йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.


5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2025 елның 04 декабрендәге 774-П номерлы боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чиге |
| • 1 | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - КМБДР белешмәләре буенча җир кишәрлекләре чикләре |
| **16:20:190101:189** | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең

**текстлы тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

| Чикне узу | | Чикне узуның тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 1 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:189 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 21,05 м ераклыкта 2 ноктасына кадәр; |
| 2 | 3 | 2 ноктасыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:189 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 36,70 м ераклыкта 3 ноктасына кадәр; |
| 3 | 4 | 3 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:189 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 11,43 м ераклыкта 4 ноктасына кадәр; |
| 4 | 5 | 4 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:190 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 11,43 м ераклыкта 5 ноктасына кадәр; |
| 5 | 6 | 5 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:190 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 11,17 м ераклыктагы 6 ноктасына кадәр; |
| 6 | 7 | 6 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:190 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 8,96 м ераклыкта 7 ноктасына кадәр; |
| 7 | 8 | 7 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:188 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 19,29 м ераклыкта 8 ноктасына кадәр; |
| 8 | 1 | 8 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә кадастр номеры 16:20:190101:188 булган җир кишәрлеге чиге буйлап 0,30 м ераклыкта 1 ноктасына кадәр. |

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**характерлы нокталары таблицасы**

| Нокта № | Җирле координаталар системасындагы нокта координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 459572.34 | 1239079.41 |
| 2 | 459569.88 | 1239100.32 |
| 3 | 459533.49 | 1239095.50 |
| 4 | 459534.26 | 1239084.09 |
| 5 | 459534.88 | 1239074.87 |
| 6 | 459545.97 | 1239076.22 |
| 7 | 459552.88 | 1239077.06 |
| 8 | 459572.04 | 1239079.38 |
| 1 | 459572.34 | 1239079.41 |

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2025 елның 04 декабрендәге 774-П номерлы боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын
**саклау предметы**

1. Объектның урнашу урыны Акъегет авылы үзәгендә, Гагарин урамының кызыл линиясе буенча.

2. Күләм-киңлек композициясе: планда квадрат конфигурация; түбә тимераягындагы биеклек билгеләре; мезонинлы ике кат.

3. Фасадларның архитектура-композицион чишелеше:

1) Стена материалы: беренче кат материалы: штукатурланган һәм буялган кирпеч. Икенче кат һәм мезонин материалы: горизонталь юнәлешле буялган такта белән тышланган бүрәнә.

2) Көньяк фасады. Беренче кат: ике яктылык күчәре (янкорманың як-ягында); тәрәзә материалы (агач) һәм пыяладан ясалган тәрәзә уемнары; почмак калаклары; катлар арасындагы кәрниз; цоколь; пыяла белән тышлау характеры һәм тәрәзә материалы (агач).

Икенче кат: ике ялган тәрәзә һәм өч яктылык күчәре; җәяле тәрәзә уемнары; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; тәрәзә төбендәге горизонталь профильле тоташтырма; түгәрәк агач пилястралар белән бүленгән тәрәзә төбе балюстрадалары; почмак пилястралары; урта күтәрмәле кәрниз.

Мезонин: өчпочмаклы формадагы фронтон; агач тышлыкның характеры («француз чыршысы» тышлык тибы); турыпочмаклы тәрәзә уемы; кыскыч белән тәмамланган сандриклы агач йөзлек; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары;

3) Көнчыгыш фасады. Беренче кат: дүрт яктылык күчәре; беренче, икенче һәм өченче яктылык күчәре бер үк зурлыкта, дүртенче яктылык күчәре киң төзек тәрәзәдән гыйбарәт; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; уеп ясалган агач йөзлекләр белән турыпочмаклы тәрәзә уемнары; почмак калаклары; катлар арасындагы кәрниз; цоколь.

Икенче кат: биш яктылык күчәре; җәяле тәрәзә уемнары; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалалары; тәрәзә төбендәге горизонталь профильле тоташтырма; түгәрәк агач пилястралар белән бүленгән тәрәзә төбе балюстрадалары; почмак пилястралары; урта күтәрмәле кәрниз.

Мезонин: өчпочмаклы формадагы фронтон; агач тышлыкның характеры; кертеп урнаштырылган җәяле тәрәзә уемы; кашлары аерып куелган агач йөзлекләр; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары;

4) Төньяк фасады. Беренче кат: почмак калаклары; цоколь; катлар арасындагы кәрниз.

Икенче кат: өч яктылык күчәре, беренче яктылык күчәре икенче яктылык


кучәреннән калак белән аерылган. Икенче яктылык кучәре – җәяле венециан тәрәзә. Өченче яктылык кучәре – җәясыман тар тәрәзә; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; урта күтәрмәле түбә кәрнизе;




5) Көнбатыш фасады: мезонинның өчпочмаклы фронтоны – урта күтәрмәле кәрниз.

4. Түбә. Түбә конфигурациясе – ике кыеклы түбә, көньяк ягында күке; түбә материалы – табаклы тимер.

*Саклау предметы комплекслы һәм фәнни тикшеренүләр, реставрация эшләре нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Акъегет авылы адресы буенча урнашкан «З.Ш.Шәфигуллин йорты», XIX гасыр ахыры, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметы таблицасы

| № т/с | Саклау предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1. | Объектның урнашу урыны Акъегет авылы үзәгендә, Гагарин урамының кызыл линиясе буенча |   Шартлы билгеләр:<br>- мәдәни мирас объекты<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Күләм-киңлек композициясе: планда квадрат конфигурация; түбә тимераягындагы биеклек билгеләре; мезонинлы ике кат |  2 нче рәсем. Көньяк-көнчыгыштан гомуми күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>3 нче рәсем. Беренче кат схемасы<br><br>4 нче рәсем. Икенче кат схемасы<br><br>5 нче рәсем. Мезонин схемасы<br>Шартлы билгеләр:<br>- тарихи капиталь диварлар – тарихи тәрәзә нары<br>- заманча корылма |
| 3. | Фасадларның архитектура-композицион чишелеше:<br>1) Стена материалы: беренче кат материалы: штукатурланган һәм буялган кирпеч. Икенче кат һәм мезонин материалы: горизонталь юнәлешле буялган такта белән тышланган бүрәнә.<br>2) Көньяк фасады. Беренче кат: ике яктылык күчәре (янкорманың як-ягында); тәрәзә материалы (агач) һәм пыяладан ясалган тәрәзә уемнары; почмак калаклары; катлар арасындагы кәрниз; цоколь; пыяла белән | <br>6 нчы рәсем. Көньяк фасадның гомуми күренеше. Ике |

тышлау характеры һәм тәрәзә материалы (агач).
Икенче кат: ике ялган тәрәзә һәм өч яктылык күчәре; җәяле тәрәзә уемнары; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; тәрәзә төбендәге горизонталь профильле тоташтырма; түгәрәк агач пилястралар белән бүленгән тәрәзә төбе балюстрадалары; почмак пилястралары; урта күтәрмәле кәрниз.
Мезонин: өчпочмаклы формадагы фронтон; агач тышлыкның характеры («француз чыршысы» тышлык тибы); турыпочмаклы тәрәзә уемы; кыскыч белән тәмамланган сандриклы агач йөзлек; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары

ялган тәрәзә



7 нче рәсем. Көньяк фасадка гомуми күренеш

3) Көнчыгыш фасады.
Беренче кат: дүрт яктылык күчәре; беренче, икенче һәм өченче яктылык күчәре бер үк зурлыкта, дүртенче яктылык күчәре киң төзек тәрәзәдән гыйбарәт; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; уеп ясалган агач йөзлекләр белән турыпочмаклы тәрәзә уемнары; почмак калаклары; катлар арасындагы кәрниз; цоколь.
Икенче кат: биш яктылык күчәре; җәяле тәрәзә уемнары; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалалары; тәрәзә төбендәге горизонталь профильле тоташтырма; түгәрәк агач пилястралар белән бүленгән тәрәзә төбе балюстрадалары; почмак пилястралары; урта күтәрмәле кәрниз.



8 нче рәсем. Көнчыгыш фасадның гомуми күренеше

| | | |
|---|---|---|
| | Мезонин: өчпочмаклы формадагы фронтон; агач тышлыкның характеры; кертеп урнаштырылган җәяле тәрәзә уемы; кашлары аерып куелган агач йөзлекләр; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары<br>4) Төньяк фасады. Беренче кат: почмак калаклары; цоколь; катлар арасындагы кәрниз.<br>Икенче кат: өч яктылык күчәре, беренче яктылык күчәре икенче яктылык күчәреннән калак белән аерылган. Икенче яктылык күчәре – җәяле венециан тәрәзә. Өченче яктылык күчәре – җәясыман тар тәрәзә; тәрәзә материалы (агач) һәм тәрәзә пыялалары; урта күтәрмәле түбә кәрнизе<br>5) Көнбатыш фасады: мезонинның өчпочмаклы фронтоны – урта күтәрмәле кәрниз | <br>9 нчы рәсем. Төньяк фасадның гомуми күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>10 нчы рәсем. Көнбатыш фасадның гомуми күренеше |
| 4. | Түбә. Түбә конфигурациясе – ике кыеклы түбә, көньяк ягында күке; түбә материалы – табаклы тимер | <br>11 нче рәсем. Көнчыгыштан күренеше<br><br>12 нче рәсем. Көньяктан күренеше |